# Тартым алмашлыклары

(Дәрескә презентация.)

Төзүче: Мингазова Илсия Ракиповна

Гыйлемнән артык - байлык, наданлыктан артык фәкыйрьлек юктыр.

Ризаэддин Фәхреддин

# Алмашлык

- мөстәкыйль сүз төркеме
- исем, сыйфат, сан һәм рәвешне алыштырып килә
- ясалышы ягыннан:

1. тамыр: мин, ул, кем, үз...
2. ясалма: ниндидер, кемнеке, барлык...
3. кушма: берninди, һичкем...
4. парлы: теге-бу, андый-мондый...
5. тезмә: әллә ни, теләсә кем...

- җөмләдә ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл булып килә ала
- мәгънә ягыннан төркемчәләре:
1. Зат: мин, син, без
2. Тартым: минеке, синеке, үзебезнеке, кемнеке
3. Күрсәтү: бу,теге,шул,шундый
4. Сорау: кем, ничек, нинди
5. Билгеләү: үз, һәр, барлык
6. Билгесезлек: кемдер, нәрсәдер, әллә нинди,әллә кайда
7. Юклык: беркем, һичнәрсә, берни, һичкая

# Синеке – илнеке

Бу таулар да синеке.
Елгалар да, таллар да,
Кышкы ап-ак бураннар да,
Җәйге алсу таңнар да,
Күргән, ишеткән, тойган
Һәммә нәрсә синеке.
Ә үзең син кемнеке?
Ә син Туган җирнеке!
Сөенечләр китерсәң дә,
Көенечләр китерсәң дә -
Барсы газиз илнеке.

Равил Фәйзуллин

# Тартым алмашлыклары

-Предметның кемнеке, кайсы затныкы икәнен белдерә

-Башка төр алмашлыкларга –ныкы, -неке (-еке) кушымчалары ялганып ясала

-Җөмләдә ия, хәбәр, тәмамлык булып килә

- Килеш, сан белән төрләнә

# Өй эше:

- Р. Фәйзуллин шигырьләреннән өзекләр язып алу, алмашлыкларны табып, төркемчәләрен күрсәтү
- Төрле алмашлыклар кулланып, “Язгы каникуллар” дигән темага кечкенә инша язарга

“Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә - тәрбияле баладыр…”

Р.Фәхреддин